КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 июль г.Казань № 539

2024 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 июль, 539 нчы
карары белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында
почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау
максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 ел, 25 октябрь, 1782 нче карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе бүлекләрен саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) – федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – почта оешмасы, субсидияләр) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия алучыга субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Министрлык тора.

4. Субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлеше – почта элемтәсе бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт хакына өстәмә түләүләрне (хезмәт өчен түләүгә карата түләүләрне исәпкә алып) гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе бүлекләрен саклап калу чараларын гамәлгә ашыру.

5. Субсидия алучыны сайлап алу (алга таба – сайлап алу), ппочта оешмасының сайлап алу критерийларына туры килү-килмәвеннән һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратыннан чыгып, почта оешмалары тарафыннан

сайлап алуда катнашуга җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) сорату юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Сайлап алу критерийлары:

почта оешмасы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

почта оешмасының Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында почта элемтәсе бүлекләре бар.

7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

8. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://digital.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт), заявкалар кабул ителә башлау көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп урнаштырыла:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү максатларын;

ирешү өчен әлеге Тәртипнең 20 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәләрен (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәләре);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә почта оешмасына карата таләпләрне һәм почта оешмасы тарафыннан аның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 13 – 16 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

почта оешмасына сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.

9. Сайлап алуны үткәрү турында игълан куелган айдан алдагы айның 1 числосына түбәндәге таләпләргә туры килсә, почта оешмасына сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителә:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

почта оешмасының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

үзгәртеп оештыру (почта оешмасына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык

процедурасы билгеләнмәү, почта оешмасының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки почта оешмасының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

10. Сайлап алуда катнашу өчен почта оешмасы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә почта оешмасы турында, аның тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу үткәрүгә бәйле почта оешмасы турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык;

почта оешмасының җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган почта оешмасының гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен теркәп);

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча салым чорына оешма мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе, Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда салым декларациясе телекоммуникация элемтә каналлары буенча җибәрелүен һәм салым органы тарафыннан алынуын раслый торган квитанция һәм хәбәрнамә, аларга түләү документларының расланган күчермәләре теркәлә;

салым органы тарафыннан исәпләнгән транспорт салымы, оешмалар мөлкәтенә салым, җир салымы суммалары турындагы хәбәрнең күчермәсе, шулай ук транспорт салымын һәм җир салымын түләүнең дөреслеген, тулылыгын һәм үз вакытында башкарылуын раслый торган документлар, шул исәптән почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) башка вшкаләтле зат тарафыннан расланган түләү документларының күчермәсен;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, ирекле формада язылган субсидия күләменең исәп-хисабы буенча белешмә кәгазе;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, ирекле формада язылган заявка бирү датасына Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында гамәлдә булган почта элемтәсе бүлекләре саны турында белешмә кәгазе;

бердәм салым счетында почта оешмасының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән бурыч күләме булмавын яки артмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтелгән (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан артып китә торган (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) Россия юридик заты булмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, почта оешмасының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы булмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган,

почта оешмасының үзгәртеп оештыру (почта оешмасына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, почта оешмасының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган гарантия хаты;

почта оешмасы җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан имзаланган, дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат, почта оешмасының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын раслый торган гарантия хаты.

Почта оешмасы тарафыннан әлеге пунктның сигезенче абзацында каралган документ тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр бите номерланган, почта оешмасы җитәкчесенең яки тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле вәкилнең (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) үз кулы белән имзасы куелган һәм мөһер сугылган булырга тиеш.

11. Бер почта оешмасы бер генә заявка бирергә мөмкин.

12. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

почта оешмасының әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында почта оешмасы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

почта оешмасының әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

13. Министрлык заявканы кергән көнне, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кабул итә һәм терки.

14. Заявкаларны карап тикшерү максаты белән Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү буенча алты кешедән торган комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия

составына Министрлык хезмәткәрләре һәм Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре арасыннан Комиссия рәисе, әгъзалары керә.

Комиссия эше аның утырышларында башкарыла. Утырыш, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы булып санала. Карар утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлары тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч тавыш булачак.

Заявка теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә Комиссия заявканы һәм аңа теркәлгән, әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә.

Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары тарафыннан имза куела һәм Комиссия утырышы үткәрелгән көнне Министрлыкка тапшырыла.

15. Министрлык беркетмә нигезендә сайлап алуда җиңүчене билгели һәм беркетмәгә имза куелганнан соң өч эш көне эчендә сайлап алучыга субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Министрлык карары боерык белән рәсмиләштерелә.

Әгәр әлеге Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә берничә почта оешмасы туры килгән булса, сайлап алуда җиңүче дип заявканы беренче булып биргән почта оешмасы танылa.

Заявканы кабул итмәү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә бу хакта почта оешмасына язмача хәбәр итә.

16. Сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган өченче календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм рәсми сайтта урнаштырыла, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

17. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = I_i + T_i + Z_i,$$

монда:

$I_i$ – салым чоры өчен субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына фактта түләнгән оешмалар мөлкәтенә салым суммасы;

$T_i$ – салым чоры өчен субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына фактта түләнгән транспорт салымы суммасы;

$Z_i$ – салым чоры өчен субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына фактта түләнгән җир салымы суммасы.

Әлеге Тәртип максатларында салым чоры булып субсидия бирү елына кадәрге календарь ел санала.

18. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт.

Учреждение кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

19. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

20. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

2024 елда субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе бүлекләре хезмәткәрләренең хезмәт хакына өстәмә түләүләрне (хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнә торган акчаны исәпкә алып) 2024 елның 31 декабренә кадәр алынган субсидия күләменнән кимрәк булмаган күләмдә тәэмин итү;

Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе бүлекләрен заявка бирү датасына булган дәрәҗәдән түбәнрәк булмаган дәрәҗәдә саклап калу.

21. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

22. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

23. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра. Хисаплар, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча тапшырыла.

24. Министрлык әлеге Тәртипнең 23 пунктында күрсәтелгән хисап тапшырылган көннән алып биш эш көне эчендә аны тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап кабул итү турында;

хисап Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча бирелмәгән очракта, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны кабул итеп алмау турында.

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны кабул итеп алмау турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә субсидия алучыга, бозуларны бетерү срогын күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр итә.

25. Министрлык субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

26. Субсидия субсидия алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы һәм (яисә) субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар тарафыннан субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар һәм тәртип бозылган очракта;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта.

27. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән субсидияне ирекле кире кайтару срогы бозылган очракта, Министрлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

28. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

29. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.